ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының үзләренең сайлау округындагы эше турында мәгълүмат тапшыру тәртибе хакында» 2011 елның 21 апрелендәге 1560-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының үзләренең сайлау округындагы эше турында мәгълүмат тапшыру тәртибе хакында» 2011 елның 21 апрелендәге 1560-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарының кушымтасына (2014 елның 14 апрелендәге 3473-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2011 елның 21 апрелендәге
1560-IV ДС номерлы
карарына кушымта

20___ елның ___ яртыеллыгы өчен
_______________ сайлау округындагы эше хакында
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты
МӘГЪЛҮМАТЫ

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары утырышлары эшендә катнашу | |
| 2. | Сайлаучылар белән очрашулар, округтагы башка чаралар (җыелышлар, митинглар, пикетлар, конференцияләр, «түгәрәк өстәлләр» һ.б.) | |
| 3. | Гражданнарны кабул итү даталары | |

| | | |
|---|---|---|
| 4. | Сайлау округында кабул ителгән гражданнар саны | |
| 5. | Каралган мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны, шул исәптән: | |
| | – интернет-кабул итү аша | |
| | – электрон почта буенча | |
| | – почта буенча | |
| | – шәхси кабул итү барышында | |
| | – башка төр кабул итү чаралары буенча | |
| 6. | Түбәндәге тематикалар буенча мөрәҗәгатьләр саны: | |
| | – дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге, шул исәптән: | |
| | а) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы адресына гражданнарның тәкъдимнәре (шул исәптән законнарны камилләштерү буенча) | |
| | б) Татарстан Республикасы Президенты, дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, муниципаль берәмлекләр җитәкчеләре адресына гражданнарның тәкъдимнәре | |
| | в) гражданнарның башка тәкъдимнәре (шул исәптән вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр) | |
| | – икътисад, сәнәгать | |
| | – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек | |
| | – транспорт һәм юл хуҗалыгы | |
| | – төзелеш, архитектура һәм торак шартларын яхшырту | |
| | – коммуналь хезмәтләр күрсәтү | |
| | – экология һәм табигать ресурслары | |
| | – мәгариф, фән һәм мәдәният | |
| | – сәламәтлек саклау | |
| | – хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау | |
| | – законлылыкны һәм хокук тәртибен тәэмин итү | |
| | – башка мәсьәләләр | |
| 7. | Түбәндәге ташламалы категорияләргә кертелүче мөрәҗәгать итүчеләр саны: | |
| | – Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннары һәм инвалидлары | |
| | – Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары | |
| | – тыл хезмәтчәннәре, хезмәт ветераннары, | |

| | | |
|---|---|---|
| | пенсионерлар | |
| | – инвалидлар, инвалид балалар | |
| | – ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар | |
| | – күпбалалы гаиләләр | |
| | – яшь гаиләләр | |
| | – эшсезләр һәм вакытлыча эшләмәүчеләр | |
| 8. | Гражданнарга уңай җавап бирелгән мөрәҗәгатьләр саны | |
| 9. | Гражданнарга аңлатмалар бирелгән мөрәҗәгатьләр саны | |
| 10. | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә җибәрелгән депутат мөрәҗәгатьләре саны | |

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты ___________ ______________________________
(имза) (фамилиясе, инициаллары)

дата».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2019 елның 14 ноябре
№ 133-VI ДС